СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
**15 август, 2024 ел**

**КАРАР**
**№ 436**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 33 статьялары, Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2024 елның 12 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәләре, Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2024 елның 12 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 31 мартындагы 160 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов